КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 декабрь г.Казань № 1228

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карары белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 сентябрь, 879 нчы карары белән расланган Наркотикларга каршы өлкәдә проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Министрлык, конкурс үткәрү срогы башланганга кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм үзенең рәсми сайтында конкурс үткәрү турында белдерү урнаштыра.

Конкурс үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

конкурс үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул конкурс үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 37 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләре;

бу Тәртипнең 15 һәм 16 пунктлары нигезендә конкурста катнашучыларга карата таләпләр һәм конкурста катнашучыларның бу таләпләргә туры килүен раслау өчен алар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 20 – 28 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

конкурста катнашучыларга конкурс үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатма бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

конкурста җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы шартнамәгә имза куелырга тиешле срок;

конкурста җиңүчене субсидия бирү турындагы шартнамәне төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

конкурс нәтиҗәләрен бердәм порталда һәм рәсми сайтта урнаштыру датасы (ул конкурста җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән соңрак була алмый);

субсидия бирү максатлары;

конкурс үткәрү шартлары.

Конкурс үткәрү чорында конкурс үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләре, әгәр дә сорату Министрлыкка заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча керсә, Министрлык тарафыннан конкурста катнашучыларга Министрлыкка тиешле сорату кергән датадан биш эш көне эчендә электрон документ рәвешендә кергән соратуда күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки язма рәвештә кергән соратуда күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә бирелә.»;

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«проектны тормышка ашыру срогы 12 айдан артмаска тиеш. Проектны тормышка ашыруны тәмамлау срогы субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 октябреннән соңрак булмаска тиеш.»;

32 пунктның өченче абзацында «субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта:

өченче абзацта «субсидия бирелгән елның 31 декабре хәленә карата» сүзләрен «проектны тормышка ашыруны тәмамлаган, әмма субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 октябреннән соңрак булмаган дата хәленә карата» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «субсидия бирелгән елның 31 декабре хәленә карата» сүзләрен «проектны тормышка ашыруны тәмамлаган, әмма субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 октябреннән соңрак булмаган дата хәленә карата» сүзләренә алмаштырырга;

38 пунктта «субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләренә алмаштырырга, «субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча» сүзләрен «квартал саен арта бара торган йомгак белән, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 көненнән дә соңга калмыйча, проектны тормышка ашыру срогы чыкканга кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

40 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«40. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 15 октябренә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин